





Хакимовлар гаиләсе – Балтачыбызда өч бала тәрбияләүче үрнәк гаиләләрнең берсе. Гаилә башлыгы Нияз Филсурович Норма профессиональ – һөнәр лицеенда директор, ә тормыш иптәше – Гүзәл Карамовна гимназиядә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Алар мөгәллим һәм спортны сөючеләр буларак, гаиләдә физик тәрбиягә нык игътибар бирәләр. Уллары Ильяс һәм кызлары Нәргизә гимназия һәм район күләмендә уздырылган төрле спорт ярышларында актив катнашалар һәм призлы урыннарны яулыйлар. Ә балалар бакчасында тәрбияләнүче Наил абый һәм апасынан бер дә калышмый: чаңгыда һәм тимераякта шуа, җинел атлетика белән шөгыльләнә, бокс белән кызыксына. Киләчәктә ул спортта зур җиңүләр һәм данлыклы спорт исемнәренә лаек булучы ир-егет булып үсәчәк.